Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча муниципаль берәмлеге
Арча шәһәре
Башкарма комитеты
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча муниципаль берәмлеге
Арча шәһәре
Башкарма комитеты
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

# КАРАР

«27» гыйнвар 2023 ел № 13

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча шәһәре башкарма комитетының 2021 елның 28 апрелендәге 50 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча шәһәре башкарма комитетының 28.04.2021 ел, №50 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктта «муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) икенче абзацтагы 12 пунктта «муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan/ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бащкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Ф.Касыймов